**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Первомайская ул., д.39, г. Лаишево, 422610
Тел: 8 (84378) 2-51-51
Факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

Беренче май ур., 39 нчы йорт, Лаеш ш., 422610
Тел: 8 (84378) 2-51-51
Факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

**2022елнын 27 июне** **49-РС номер**

## КАРАР

### Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлегенең генераль планын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлегенең 2022 елның 4 мартындагы 10-53/2531номерлы генераль планы проектына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты бәяләмәсен карап, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2022елның 18 февралендәге гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлегенең генераль планы проектын расларга(кушымта 1).
2. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә.
4. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлегенең генераль планын раслау турында» 2018 елның 27 декабрендәге 77-РС номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карары әлеге карар үз көченә кергән вакыттан үз көчен югалткан дип танырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары И. П. Шитовка йөкләнә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы Рәисе** **И.Ф. Зарипов**